ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«күпфатирлы йортның һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектының әзерлек дәрәҗәсе турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең мондый объектларның әзерлек дәрәҗәсен һәм өлешле төзүдә катнашуга төзелгән шартнамәләрнең санын билгели торган критерийларына туры килә торган бәяләмәләр бирү һәм тиешле белешмәләрне торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 05 апрель
№ 24-ТРЗ